**Татар телендә гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры биремнәре *җаваплары***
**2021-2022 нче уку елы**
**5 нче сыйныф**

**Максималь балл – 45**

## I. Тестны эшләгез. (10 балл)

1. Фонетика нәрсәне өйрәнә? ***(1 балл)***

а) сүз ясалышын

ә) сүз байлыгын

**б) сөйләм авазларын**

в) сүз төзелешен

2. Татар телендә ничә сузык аваз бар? ***(1 балл)***

а) 9

ә) 13

**б) 12**

в) 6

3. Сүзнең транскрипциясендә хата булган вариантны билгеләгез. ***(1 балл)***

а) [сөлгө]

ә) [борон]

б) [болот]

в) **[қөзгө]**

4. Мәкальнең дәвамын билгеләгез. ***(1 балл)***

Үзең сөйли башлаганчы,

а) кеше сүзен тыңлап торма.

**ә) кеше сүзен тыңлап бетер.**

б) аның сүзен тыңлама.

в) кеше сүзен бүлдереп тор.

5. Татар телендә ничә тартык аваз бар? ***(1 балл)***

**а) 28**

ә) 24

б) 20

в) 12

6.  Татар телендәге кыска сузыклар рәтен билгеләгез. ***(1 балл)***

а) а, ә, о, ы

ә) о, ы, ү, и

**б) о, ы, е, ө**

в) ә, ы, у, о

7. *Карт төлке* фразеологизмын башка бер сүз белән алыштырыгыз. ***(1 балл)***

а) акыллы

**ә) хәйләкәр**

б) ялкау

в) тынгысыз

.

8. Орфография нәрсәне өйрәнә? ***(1 балл)***

а) сүзләрнең дөрес әйтелешен

ә) сөйләм авазларын

б) сүз төзелешен

**в) дөрес язу кагыйдәләрен**

9. Искергән сүзне билгеләгез. ***(1 балл)***

а) бәхет

**ә) гакыл**

б) туган

в) гасыр

10. Сыйфатлар рәтен табыгыз ***(1 балл)***

а) эреләт, яшелләт, матурлан

ә) сызык, килен, белем

**б) хәрәкәтчән, уйчан, сакчыл**

в) татарча, русча, инглизчә

## II. Теоретик бирем

Омонимнар һәм аларның төрләре турында языгыз. Һәр төренә икешәр мисал китерегез. **(8 балл)**

Әйтелешләре һәм язылышлары бер үк, әмма мәгънәләре арасында уртаклык булмаган сүзләр **омонимнар** дип йөртелә. Омонимнарның дүрт төре бар.

**Саф лексик омонимнар** – аваз составы ягыннан бер-берсенә охшаш тамыр сүзләр: *туп, ат.*

**Омофоннар** – әйтелешләре бер, язылышлары төрле булган сүзләр: *сыер чык, сыерчык; карт аю, картаю.*

**Омографлар** – язылышлары бер, әйтелешләре төрле булган сүзләр: *басмá, бáсма; алмá, áлма.*

**Омоформалар** – бер грамматик формада гына омоним булган сүзләр: *күркәм* – сыйфат *(красивый), күркәм* – исем *(мой индюк); өй* – исем *(дом), өй* – боерык фигыль *(сложи в кучу)*.

## III. Гамәли-иҗади бирем (27 балл)

1. Төшеп калган хәрефләрне куеп, текстны күчереп языгыз. **(3 балл: бер хәреф – 0,3 б.)**

Көз

Дөн**ья** тынып калды. Көз килде дә ка**е**н **яф**ракларын сап-сары бу**я**уга манды. Ә көзге җил минем дустымны селкетте. Аның сары яфраклары җиргә

коелды. Бу көннәрдә кошлар да ерак-ерак илләргә киттеләр. Каен агачы я**п**-ялангач торып калды. Аңа бик салкын булыр инде.

Ә мин борч**ы**лмыйм. Тиздән ак ту**н** кигән Кыш бабай килер. Ул җирне ап-ак ю**р**ган белән капл**а**р.

Нәби Дәүлидән

1. ***Каен*** сүзенә язмача фонетик анализ ясагыз. **(6 балл)**

Каен **[**ҡ а° й ы́ н**]**

Ка-ен

Хәрефләр: к, а, е, н.

Авазлар:

**[**ҡ**]** – саңгырау тартык аваз, яңгырау пары [ғ],

[а°] – калын сузык аваз,

[й] – парсыз яңгырау тартык аваз,

[ы] – калын сузык аваз,

[н] – парсыз яңгырау тартык аваз.

___________

4 х., 5 ав.

2. ***Көзге, кошлар*** сүзләрен мәгънәле кисәкләргә таркатыгыз. **(2 балл)**

Көз (тамыр) - ге (сыйфат ясагыч кушымча); кош (тамыр) - лар (форма ясагыч кушымча (яки модальлек кушымчасы)

3. ***Баш*** сүзенннән биш тамырдаш сүз ясап языгыз. **(5 балл)**

Юл - юллы, юлсыз, юлчы, юлдаш, юллык (юллау, юлдашсыз).

4. ***Ману, селкетү*** сүзләренең синонимнарын языгыз. **(1 балл)**

Ману - буяу; селкетү - тирбәтү.

5. “Ак тун кигән Кыш бабай” темасына 9-10 җөмләдән торган бәйләнешле текст төзеп языгыз. **(10 балл)**